ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 04 2019 г. № 212

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру административ регламентын яңа теркәлгән редакциядә раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруның административ регламентын яңа теркәлгән редакциядә расларга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә контрольне һәм күзәтчелекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү регламентын раслау турында» 2010 елның 14 октябрендәге 1349-нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Җәмәгатьчелек һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә.Хажиевкә йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 24-нче апрель
212-нче номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелегенең
АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Түбән Кама муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) вакытын һәм эзлеклелеген (алга таба – дәүләт функциясе), шулай ук дәүләт фукциясен башкарганда дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр, юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели (алга таба – Административ регламент).

1.2. Дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый актлар исемлеге:

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 07.01.2002, № 1, 1 статья);

- Россия Федерациясе Торак кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1, 14 статья);

- «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1, 40 статья);

- «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 08.05.2006, № 19, 2060 статья);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.12.2008, № 52, 6249 статья);

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 31.07.2006, № 31, № 31, 3451 статья);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2006 елның 21 апрелендәге 233 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 01.05.2006, № 18, 2001 статья);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 12.07.2010, № 28, 3706 статья);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүмат алар карамагында булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сората һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 02.05.2016, №18, 2647 статья);

- Россия Федерациясе региональ үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы («Российская газета», 14.05.2009, № 85);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 13.04.2015);

- Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын исәпләү тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2006 елның 30 ноябрендәге 06-137/пз-н номерлы боерыгы (Российская газета, 31.01.2007, № 19);

- Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисаплылык формаларын тутыру буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2006 елның 12 гыйнварындагы 06-2/пз-н номерлы боерыгы (Башкарма хакимият федераль органнарының норматив актлары бюллетене, 20.03.2006, № 12);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә торган күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектына карата төзүченең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 2016 елның 9 декабрендәге 914/пр номерлы боерыгы (Российская газета, 13.01.2017, № 6);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 30.12.2016);

- «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, 03.08.2004, № 155-156);

- «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» (Татарстан Республикасы, 28.12.2007, № 259);

- Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен төзелешкә гражданнарның акчаларын җәлеп итә торган затлардан алынган кирәкле мәгълүматлар һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары, (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 18.10.2013, № 77, 2609 ст.);

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм архитектура идарәсе турында нигезләмә.

1.3. Дәүләт функциясен үтәү Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының өлешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан башкарыла.

1.4. Административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр:

- контроль субъектлары - административ регламентның 1.7 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, аларга карата дәүләт функциясе башкарыла торган затлар;

- контроль объектлары - составына өлешләп төзелеш һәм өлешләп төзелештә катнашучылар акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырылган төзелеш кергән күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары.

1.5. Дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру барышында, Бүлек билгеләнгән тәртиптә Түбән Кама муниципаль районының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

1.6. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы.

Тикшерү предметы булып, 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын

төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларның мәҗбүри таләпләрне үтәве тора.

1.7. Аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар:

Контроль субъектлары булып, 214-ФЗ Федераль закон нигезләмәләрендә каралган күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тора.

1.8. Дәүләт функцияләрен үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау.

1.8.1. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча тикшерү үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары булмаганда, акт өч нөсхәдә төзелә , аларның берсе аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка тапшырыла яисә җибәрелә.

1.8.2. Тикшерү барышында мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта:

1) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча акт өч нөсхәдә төзелә, аларның берсе аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка тапшырыла яисә җибәрелә;

2) административ регламентка 1нче кушымта нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелә.

1.8.3. Төзүчеләрнең мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга карата мәҗбүри таләпләрне үтәүләрен тикшерү нәтиҗәләре буенча административ җаваплылык каралган закон таләпләрен бозу ачыкланган очракта төзелә:

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзүчеләрнең мәгълүмат ачуга һәм урнаштыруга карата билгеләнгән таләпләрне тикшерү акты;

- административ регламентка 1-нче кушымта нигезендә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә.

Тикшерү материаллары хокук саклау органнарына, шул исәптән Түбән Кама шәһәре прокуратурасына гамәлдәге вәкаләтләр кысаларында җибәрелә.

1.8.4. Төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлек алып бару турындагы квартал саен хисаплылыгын тикшерү нәтиҗәләре буенча күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында законда билгеләнгән таләпләрне бозу һәм документлар булмауны ачыклаганда:

- исәпкә алу журналында теркәлергә тиеш булган, административ регламентка 2-нче кушымта нигезендә форма буенча тикшерү акты төзелә;

- административ регламентка 1нче кушымта нигезендә форма буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелә.

1.8.5. Өлешләп төзү объектын өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру вакытын бозу һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 8 статьялары таләпләрен үтәмәү, шулай ук төзүченең финанс тотрыклылыгы нормативларының туры килмәве ачыкланганда, административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелә.

1.8.6. Җинаять билгеләре ачыкланган очракта, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе хокук саклау органнарына, җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, җинаять эше билгеләре булган мәҗбүри таләпләрне бозу фактларын ачыклау белән бәйле материаллар җибәрә.

1.8.7. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау нәтиҗәләре буенча түбәндәге чаралар үткәрелә:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында аларны үтәү бәяләмәсе дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре исемлеген, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын, дәүләт функцияләрен үтәү практикасын гомумиләштерү практикасын, шул исәптән аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән мәҗбүри таләпләрне бозу аеруча еш очрый торган очракларны күрсәтеп урнаштыру;

- аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү.

1.8.8. Дәүләт функциясен үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган күзәтчелек буенча чараларны планлаштыру нәтиҗәләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында раслана һәм урнаштырыла:

1) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, таләпләрне бозуларны профилактикалау программасы;

2) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнештә булмаган контроль буенча чаралар үткәрүгә бирем;

3) дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затларга карата планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы.

1.9. Бүлек хезмәткәренең хокуклары һәм бурычлары.

1.9.1. Дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләргә ия булган вазыйфаи зат булып бүлекнең баш белгече тора.

1.9.1.1. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашырганда вазыйфаи затның хокуклары.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашырганда бүлекнең вазыйфаи заты хокуклы:

1) исемлек буенча (4 нче кушымта) тикшерү объектлары булып торган яки тикшерү предметына караган документларны, мәгълүматны соратырга һәм алырга);

2) хезмәт таныклыгын һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең тикшерү үткәрү турындагы боерыкның күчермәләрен күрсәтеп, алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне тикшерү максатларында, аларга карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затларның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урыннарга тоткарлыксыз барып керү;

3) исемлек буенча (4 нче кушымта) тикшерү объектлары булып торган яки тикшерү предметына караган документларны, мәгълүматны соратырга һәм алырга;

4) аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлардан телдән яки язмача аңлатмалар алу;

5) тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә, түләүсез нигездә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалардан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүматны, шул исәптән электрон формада, соратырга һәм алырга;

6) тикшерү актларына кул кую һәм танышу өчен аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган вәкаләтле вәкилгә, башка вазыйфаи затка тапшыру;

7) ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр имзаларга;

8) федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гаеплеләрне җаваплылыкка тарту турында мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны (документларны) хокук саклау органнарына һәм судларга җибәрергә;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларга карата дәүләт функциясе башкарыла торган затларга шикаять биргәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

10) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 15 пунктында каралган нигезләр буенча күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле төзүче эшчәнлеген гамәлгә ашыруны билгеле вакытка туктатып тору турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә;

11) 214-ФЗ номерлы Федераль закон яки аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлар таләпләрен берничә тапкыр яки тупас бозу, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затны юкка чыгару турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә.

1.9.1.2. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашырганда вазыйфаи затның бурычлары.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда вазыйфаи зат бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

2) аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясе законнарын үтәргә;

3) аның билгеләнеше нигезендә, аны үткәрү турында үз приказлары нигезендә тикшерү үткәрергә;

4) җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның вәкаләтле вәкиленә комачауламаска, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздырганда катнашырга һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

5) җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның вәкаләтле вәкиленә, тикшерү уздырганда катнашучы аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

6) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның вәкаләтле вәкилен, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

7) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның вәкаләтле вәкилен, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштыру;

8) аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять биргәндә, үз гамәлләренең нигезле булуын исбатларга;

9) Административ регламентта билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын үтәргә;

10) аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлардан Россия Федерациясе законнары белән каралмаган документлар һәм башка белешмәләр таләп итмәскә;

11) җитәкче яки аңа карата дәүләт функциясе башкарыла торган башка вазыйфаи зат, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тәкъдим ителгән элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатма һәм документларны карау;

12) тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, юридик затка ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирергә;

13) тикшерү үткәргәндә, орган, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, ачыкланган бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү һәм ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җәлеп итү буенча чаралар күрергә тиеш;

14) Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм Россия Федерациясе законнары белән саклана торган дәүләт, коммерция, хезмәт, башка серне тәшкил итүче мәгълүматны таратмаска;

15) аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында, аны үткәрү нигезләре 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән урынга чыгып тикшерүдән тыш, аны үткәрә башлауга кадәр 24 сәгатьтән дә ким булмаган вакыт эчендә теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле

электрон имза белән имзаланган һәм аңа карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затның  электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ аша хәбәр итәргә, әгәр мондый адрес юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элек Бүлеккә тәкъдим ителгән булса.

1.9.2. Дәүләт функциясен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләргә ия булган бүлек хезмәткәре булып баш белгеч тора.

1.10. Аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.10.1. Аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар хокуклы:

1) турыдан-туры дәүләт функциясен башкарганда катнашу, дәүләт функцияләрен үтәү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) дәүләт функцияләрен үтәү предметына караган һәм 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган мәгълүматны бүлектән, аның вазыйфаи затларыннан алырга;

3) дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре белән танышуын, килешү яки алар белән килешмәүне күрсәтергә;

4) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Россия Федерациясе субъектында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә;

5) дәүләт функциясен үтәгәндә, аларның хокукларын бозуга китергән Бүлек хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә.

1.10.2. Аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар бурычлы:

1) тикшерү уздырганда, тикшерү үткәрүче Бүлекнең вазыйфаи затына вазыйфаи зат соратып ала торган документларга һәм (яки) мәгълүматка керү мөмкинлеген бирергә;

2) урынга чыгып тикшерүдә катнашучы вазыйфаи затка бина, төзелмәләр, корылмалар, биналар эшчәнлеген гамәлгә ашырганда аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар файдалана торган территориягә керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

3) мотивлаштырылган сорату алган көннән соң 10 эш көне эчендә соратуда күрсәтелгән документларны Бүлеккә җибәрергә;

4) Бүлекнең вазыйфаи затына җибәрелгән күрсәтмәләрдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерергә.

## 2. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә таләпләр

2.1. Бүлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Түбән Кама шәһәре, Мәктәп бульвары, 2А йорты.

Бүлекнең эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00-17:00;

төшке аш: 12.00-13.00.

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

2.2. Дәүләт функциясенең үтәлеше турында мәгълүмат бирелә:

1) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру аша.

2) дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча кабул итү көннәрендә һәм сәгатьләрендә шәхси кабул итү барышында шәхси мөрәҗәгать иткәндә – сишәмбе көнне, көтү вакыты 15 минуттан артмасын өчен, кабул итүгә язылучылар санын исәпкә алып, 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

3) кабул итү булмаган көннәрдә мөрәҗәгать иткәндә - (8555)41-60-44 телефоны буенча белгечтә;

4) электрон почта адресы буенча мөрәҗәгать иткәндә: otdel.ds.nk@tatar.ru;

5) гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару юлы белән;

6) документлар кабул итү өчен билгеләнгән урыннарда махсус мәгълүмати стендларда мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

7) мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына язмача мөрәҗәгатькә (гаризага) язма мөрәҗәгатьтә (гаризада) күрсәтелгән адрес буенча, шул исәптән (яисә) мөрәҗәгать итүченең электрон почтасына җавап җибәрү юлы белән.

2.3. Бүлек тарафыннан бирелә торган дәүләт функциясенең үтәлеше турында мәгълүмат булып тора:

а) үтәлүне бәяләү дәүләт күзәтчелеге предметы булган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләре исемлеге, шулай ук норматив хокукый актлар текстлары;

б) гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр;

в) хокук бозуларны булдырмау максатларында кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән тикшерү субъектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне тикшереп торуны (күзәтүне) гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү;

г) дәүләт функцияләрен үтәгәндә бүлекнең вәкаләтле затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

д) планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планнары;

е) тикшерүләр үткәрү нәтиҗәләре турында һәм ачыкланган бозулар нәтиҗәләрен туктату һәм (яки) бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат;

ж) Административ регламент тексты.

2.4. Дәүләт функциясен үтәү түләүсез нигездә башкарыла.

2.5. Дәүләт функциясен үтәү сроклары.

2.5.1. Дәүләт функциясен үтәү сроклары:

1) квартал саен хисап тикшергәндә - төзүченең хисабы кергән көннән алып 60 эш көненнән дә артык түгел;

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында каралган планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәргәндә – 20 эш көненнән дә артык түгел;

3) төзүчеләрнең мәгълүматны ачу һәм урнаштыруа билгеләнгән таләпләрне тикшергәндә - квартал саен, 1 нән 25енә кадәр;

4) төзүче һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә биргәндә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартканда – 30 календарь көннән дә артык түгел.

2.5.2. Россия Федерациясе законнары һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1.1 өлешендә билгеләнгән тиешле шартлар нигезендә теркәлгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына карата: хуҗалык җәмгыятьләре, хуҗалык партнерлыклары, җитештерү кооперативлары, кулланучылар кооперативлары һәм шәхси эшмәкәрләр (алга таба – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары) – планлы урынга чыгып тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы артмаска тиеш:

- кече предприятие өчен (моннан алдагы календарь елында 100 кешегә кадәр тәшкил иткән эшчеләрнең исемлек буенча уртача саны) – елына 50 сәгать;

- микропредприятие өчен (моннан алдагы календарь елында 15 кешегә кадәр тәшкил иткән эшчеләрнең исемлек буенча уртача саны) – елына 15 сәгать.

2.5.3. Квартал саен хисаплылыкны тикшерү, өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларны төзүчеләр тарафыннан максатчан файдалануын тикшерү өлешендә дәүләт функцияләрен үтәү срогы төзүче тарафыннан соратып алына торган документларны тапшыру өчен кирәкле вакытка озайтылырга мөмкин, ләкин 10 эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.6. Дәүләт функциясе башкарылуын туктатып тору күздә тотылмый.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Административ процедураларның тулы исемлеге.

Дәүләт функциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) контрольдә тотылырга тиешле субъектлары (объектлары) исемлеген алып бару (алга таба - Исемлек);

2) дәүләт функцияләрен үтәүне тәэмин итү максатларында башкарыла торган контроль (күзәтчелек) чараларын планлаштыру;

3) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, таләпләрне бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү;

4) төзүче белән үзара бәйләнештән башка мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен контрольдә тоту чараларын оештыру һәм үткәрү;

5) планлы тикшерүләр оештыру;

6) планнан тыш тикшерүләр оештыру;

7) вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган дәүләт функциясен үтәгәндә ачыкланган бозуларны бетерү һәм аны гамәлгә ашыру барышында күрсәтелгән

мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чаралар кабул итү;

8) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яки мондый бәяләмәне бирүдән мотивлаштырылган баш тарту (дәүләт хезмәте күрсәтүнең тиешле административ регламенты нигезендә);

9) күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисабын тикшерү;

10) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау.

3.2. Дәүләт функциясен үтәүнең Блок-схемасы Административ регламентка 3-нче кушымтада китерелгән.

3.3. Исемлекне алып бару.

3.3.1. Административ процедураның башлануы булып, төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы квартал саен хисаптан контрольгә алынган субъект (объект) турында мәгълүмат алу тора.

3.3.2. Исемлекне алып бару электрон һәм кәгазьләрдә башкарыла.

3.3.3. Исемлек Бүлекнең вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан алып барыла.

3.3.4. Исемлек Интернет челтәрендә рәсми сайтта урнаштырыла һәм кирәк булганда актуализацияләнә.

3.4. Дәүләт функцияләрен үтәүне тәэмин итү максатларында башкарыла торган контроль (күзәтчелек) чараларын планлаштыру.

3.4.1. Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын әзерләү һәм раслау түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) Түбән Кама шәһәрендә күпфатирлы йортларны өлешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек Бүлеге тарафыннан тикшерү үткәрү елына кадәрге елның 20 декабренә кадәр чорга муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын эшләү;

2) Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау.

3.4.2. Төзүче тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыру буенча билгеләнгән таләпләрне тикшерүне үткәрүгә карата биремне әзерләү һәм раслау түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан биремнәрне эшләү;

2) Башкарма комитет җитәкчесе, яисә вәкаләтле зат тарафыннан биремне раслау.

3.4.3. Административ гамәлләрнең нәтиҗәсе булып, төзүче тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга куелган таләпләрне тикшерүне үткәрү биремнәрен раслау һәм аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштыру тора.

3.4.4. Ел саен үткәрелә торган тикшерүләр планын әзерләү түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) тикшерү субъектларына планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын Бүлек хезмәткәре тарафыннан әзерләү һәм төзү;

2) юридик затларга (аларның филиалларына, вәкиллекләренә, аерымланган структур бүлекчәләренә) һәм шәхси эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүне дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) кызыксынган башка органнары белән килештерү;

3) субъектларга планлы тикшерү үткәрү еллык планы проектын Түбән Кама шәһәре прокуратурасына карау өчен тикшерү үткәрү елына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр җибәрү;

4) әлеге проектны карау нәтиҗәләре буенча кергән прокуратура органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, тикшерү субъектларга планлы тикшерү үткәрү еллык планы проектын эшләп бетерү, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан аны раслау, тикшерү субъектларының планлы тикшерү үткәрүнең расланган планын планлы тикшерү үткәрү елына кадәрге елның 1 ноябренә кадәр Түбән Кама шәһәре прокуратурасына җибәрү;

5) кызыксынган затларга планлы тикшерү үткәрүнең еллык планын, аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, план буенча тикшерүләрне үткәрү елына кадәрге елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча җиткерү.

План буенча тикшерүләрне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен нигез булып тора:

1) төзелешкә гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка төзелешкә рөхсәт бирү датасыннан бер ел узу;

2) Түбән Кама шәһәре территориясендә мондый затка соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланганнан соң бер ел узу;

3) тикшерү субъектлары эшчәнлеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары нигезендә планлаштырылган тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 20 июленә кадәр куркыныч-юнәлешле якын килүне кулланып билгеләнгән класска кертү.

3.4.5. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән юридик затларның эшчәнлеген билгеле бер куркыныч категориясенә кертү критерийлары нигезендә аерым класс (категория) куркынычлыгына яки аерым риск категориясенә кертү һәм планлы тикшерүләрне үткәрүнең вакыт-вакыт кабатланып торуы гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерү үткәрүнең еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары белән расланган типик форма нигезендә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.1 статьясы нигезендә куркыныч-юнәлешле якын килүне кулланып төзелә.

3.4.7. Дәүләт функциясен үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган контроль чараларын планлаштырганда, Бүлек прокуратура органнары

тәкъдимнәрен карый һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 ноябренә кадәр прокуратура органнарына җибәрә.

3.4.8. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган тикшерү субъектларына планлы тикшерүләр үткәрү планы кызыксынучы затларга аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.4.9. Административ гамәлләрнең нәтиҗәсе булып тикшерү субъектларына планлы тикшерүләр үткәрү планын раслау һәм аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тора.

3.5. Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү.

3.5.1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында, Бүлек ел саен алар тарафыннан раслана торган бозуларны профилактикалау программалары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра

Мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган мәҗбүри таләпләрне, сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару өчен аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар тарафыннан бозуларны кисәтү максатларында, вазыйфаи затлар ел саен раслана торган бозуларны профилактикалау планы нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра.

3.5.2. Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында, Бүлек:

1) «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда һәр төр дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өчен аларны тоту дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контрольнең предметы булган, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләренең исемлеген, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын урнаштыруны тәэмин итә;

2) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланмалар эшләү һәм бастыру аша, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләрен башкару һәм башка ысуллар аша. Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләрне билгеләүче яңа норматив хокукый актлар эчтәлеге турында тәкъдимнәр, гамәлдәге актларга, аларның гамәлгә керү вакытына һәм тәртибенә кертелгән үзгәрешләр, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне

гамәлгә кертүгә һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр әзерли һәм тарата,;

3) тиешле эшчәнлек өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру практикасын даими (елга кимендә бер тапкыр) гомумиләштерүне һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыруны, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының еш очрый торган очракларын күрсәтеп, мондый хокук бозуларны булдырмау максатларында, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән тәэмин итәләр;

4) әгәр дә башка тәртип федераль закон белән билгеләнмәгән булса, 294-ФЗ Федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләре нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирәләр.

3.5.3. Хәбәрнамә аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка яки аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле затка кәгазьдә почта аша җибәрелә.

3.5.4. Бүлек муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү максатлары өчен аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларның хокукларын һәм ирекләрен чикләү белән бәйле булмаган дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллануны камилләштерү һәм башка максатлар өчен хәбәрнамәне куллана.

3.5.5. Административ процедураның нәтиҗәсе булып тора:

1) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында аларны тоту бәяләмәсе дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре исемлеген, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын, дәүләт функцияләрен үтәү практикасын гомумиләштерү практикасын, шул исәптән аларга карата дәүләт функциясе башкарыла торган затлар тарафыннан кабул итәргә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының еш очрый торган очракларын күрсәтеп урнаштыру;

2 «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисабын тикшерү нәтиҗәләрен урнаштыру;

3) аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү.

3.6. Төзүче белән хезмәттәшлектән башка мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен контрольдә тоту чараларын оештыру һәм үткәрү.

3.6.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез булып, дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән өлешләп төзүдә катнашуның беренче шартнамәсен теркәү турында яисә төзүченең соңгы планлы тикшерүе тәмамланганнан соң бер ел үтүе яисә төзүчеләрнең мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга билгеләнгән таләпләрне тик-

шерүдән соң хәбәрнамә алу тора.

3.6.2. Административ процедураны үтәүдә вәкаләтле зат булып, бүлекнең баш белгече тора.

3.6.3. Административ процедура «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.3 статьясы таләпләренә туры китереп, мәгълүмат урнаштырганда төзүчеләрнең мәҗбүри таләпләрне үтәвен күзәтү рәвешендә алып барыла.

3.6.4. Тикшерү предметлары булып, төзүче тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шушы төзүче хокуклары булган электрон адрес составында домна исеме булган сайтта (алга таба – төзүче сайты) түбәндәге мәгълүматны урнаштыру тәртибе һәм сроклары тора:

1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр;

2) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 2 өлешенең 1, 3, 5 пунктларында күрсәтелгән документлар;

3) проект декларациясе;

4) төзүче һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы бәяләмәсе;

5) өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе проекты яки 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган, төзүче тарафыннан күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү өчен кулланыла торган мондый шартнамәләрнең проектлары;

6) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьялары таләпләре нигезендә мондый акчаларны эскроу счетларында урнаштыру очрагында, өлешләп төзелештә катнашу шартнамәсе буенча җәлеп итү шартлары;

7) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән документлар;

8) күпфатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, алар төзелешенең (тудыруның) хәзерге торышын чагылдыручы төзүче тарафыннан төзелә торган (тудырыла торган) фоторәсемнәре;

9) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;

10) капиталь төзелеш объектын, аңа керү һәм үтү урыннарын, җәмәгать сервитутлары, археологик мирас объектларының эш итү зоналары чикләрен урнаштыру урыннарын билгеләү белән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планлы оештыру схемасы;

11) үз акчалары күләмен һәм төзүченең финанс тотрыклылыгын исәпләү нор-

мативлары турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

12) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында мәгълүмат;

13) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә юнәлдерелгән капиталь төзелеш объектын төзи башлау, реконструкцияләү турында хәбәрнамә;

14) мондый счет номеры, вәкаләтле банк һәм аның идентификаторлары (салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры) күрсәтелгән төзүченең исәп-хисап счетын ачу яисә ябу турында мәгълүматлар;

15) 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка мәгълүмат.

3.6.5. Төзүченең рәсми сайтында өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә (тудырыла) торган һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына карата Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә (тудырыла) торган һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына карата төзүченең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләрне раслау турында» 2016 елның 9 декабрендәге 914/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр.

3.6.6. Административ регламентның 3.6.4 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче сайтында төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бүлек бәяләмәсен алганнан соң биш эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш. Административ регламентның 3.6.4 пунктындагы 11 пунктчасында күрсәтелгән фоторәсемнәр төзүченең рәсми сайтында ай саен урнаштырылырга тиеш.

3.6.7. Административ регламентның 3.6.4 пунктында күрсәтелгән документларга кертелгән үзгәрешләр төзүченең рәсми сайтында мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң биш эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш.

3.6.8. Административ регламентның 3.6.6 һәм 3.6.7 пунктларында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты 20 эш көне тәшкил итә.

3.6.9. Төзүчеләр тарафыннан мәгълүматны ачу һәм урнаштыру буенча билгеләнгән таләпләрне планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып торалар:

- 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозуны бетерү турында тикшерүче орган биргән күрсәтмәнең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан, шулай ук Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү өлешендә башка тәләпләрне үтәү срогы чыгу, әгәр күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан мондый вакыт үткәнчегә әлеге күрсәтмәдә күрсәтелгән бозулар бетерелмәгән булса;

- Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык хисабында (шул исәптән еллык) һәм (яки) проект декларациясендә күпфатирлы

йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисабына анализ үткәрү барышында күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре табылганда;

- тикшерүче органга 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларын, вәкаләтле органның актларын, җирле үзидарә органнары актларын бозу фактлары турында гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгать итүе һәм гаризалары, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясында 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, коммерциячел булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән алынган мәгълүмат керү;

- төзүченең төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк айга читкә китүе;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның мәҗбүри таләпләрен һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын бозу ачыкланган очракта, Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы күрсәтмәсе нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү үткәрү турында тикшерү органы җитәкчесе боерыгы;

- прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.2 статьясындагы 4 өлешендә каралган тикшерүче органга вәкаләтле банк хәбәрнамәсе керү.

3.6.10. Проект декларациясен тикшергәндә билгеләнә:

- проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 20, 21 статьялары таләпләренә туры килүе;

- билгеләнгән үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын үтәү.

3.6.11. Проект декларациясен тутыру тәртибенә карата таләпләр Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

3.6.12. Административ процедураны үтәүнең максималь вакыты үзгәрешләр кертелгәннән соң 30 көн тәшкил итә.

3.6.13. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 20, 21 статьялары таләпләрен бозу ачыкланган очракта, административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча тикшерү акты төзелә һәм административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә форма буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә чыгарыла.

3.6.14. Күрсәтмә анда билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш. Күрсәтелгән срокта күрсәтмәне үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия

Федерациясе кодексының 19.5 статьясында каралган административ җаваплылыкка тартыла.

3.6.15. Нигезле сәбәпләр аркасында аерым пунктларны бетерү срокларын озайту зарурлыгы очрагында, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелгән тикшерү субъекты, күрсәтмәдә күрсәтелгән сроктан да соңга калмыйча, Бүлеккә күрсәтмәне үтәү вакытын озайтуны нигезләүче документларны, үтенечнамә җибәргән вакытка җитешсезлекләрне бетерү барышы турында материалларны теркәп, күрсәтмәне үтәү срокларын озайту турында үтенечнамә җибәрергә хокуклы (алга таба – үтенечнамә).

Үтенечнамәне канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм күрсәтмәне башкаруның яңа срогын билгеләү турындагы карар Бүлек хезмәткәре тарафыннан күрсәтмәне теркәгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча Бүлеккә кабул ителә һәм тикшерү субъектына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша, шул исәптән элек тикшерү субъекты биргән электрон почта аша да җибәрелә.

3.7. Планлы тикшерүләр.

3.7.1. Тикшерүне оештыру тәртибе.

3.7.1.1. Тикшерү Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгында күрсәтелгән затлар тарафыннан гына башкарылырга мөмкин.

3.7.1.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгында күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Бүлекнең тулы исеме, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре(-ләре);

3) тикшерү уздырган вәкаләтле затларның фамилиясе, исемнәре, атасының исеме һәм вазыйфасы;

4) тикшерелүче юридик затның исеме яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, шулай ук тикшерү үткәргәндә булган җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

5) тикшерү үткәрү датасы, вакыты, озынлыгы һәм урыны;

6) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозу очракларын ачыклау турында, аларның характеры һәм күрсәтелгән хокук бозуга юл куйган затлар турында мәгълүматлар;

7) тикшерү үткәргәндә булган җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән таныштыру яисә танышудан баш тарту, аларның имзалары булу яки кул куюдан баш тарту турында мәгълүмат, шулай ук тикшерү турындагы язманы тикшерүне исәпкә алу журналына кертү турында яисә күрсәтелгән журналның юридик затта, шәхси эшмәкәрдә булмавы белән бәйле рәвештә мондый язманы кертү мөмкин булмавы турында белешмәләр;

8) тикшерү уздырган вәкаләтле затларның имзалары.

3.7.1.3. Тикшерү үткәрү турындагы боерык ике нөсхәдә имзалана, аларның

берсе Бүлектә саклана, икенчесе – тикшерү субъекты җитәкчесенә, башка вазыйфаи затка яки вәкаләтле вәкиленә имза куеп бирелә.

3.7.1.4. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затның тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелеш өчен гражданнар акчаларын җәлеп итүче затлардан алынган күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлеге турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары белән исемлеге расланган документлар тапшыру турында таләп әзерләнә. Таләп Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

3.7.1.5. Тикшерү субъекты җитәкчесе, башка вазыйфаи зат яисә вәкаләтле вәкиле үтенече буенча тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар тикшерелергә тиешле затларны Административ регламент һәм контроль (күзәтчелек) буенча чаралар үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.

3.7.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган тикшерүләр субъектларын планлы тикшерүнең еллык планы административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.7.3. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып Бүлекнең баш белгече тора.

3.7.4. Тикшерү субъектларына планлы тикшерү үткәрү турында, аны үткәрү башланырга өч эш көненнән дә соңга калмыйча, планлы тикшерү үткәрү турында Бүлек боерыгы җибәрү аша һәм түбәндәге ысулларның берсе белән документларны тапшыру турында таләпләр аша Бүлек хәбәр итә:

- тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша җибәрергә;

- көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ ярдәмендә;

- юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча, әгәр мондый адрес элек бүлеккә тәкъдим ителгән булса (шул исәптән тикшерелә торган затның проект декларациясендә күрсәтелгән);

- йомышчы аша кул куеп;

- мәгълүмат алу мөмкинлеген бирә торган башка ысул белән.

3.7.5. Планлы тикшерү Административ регламентның 3.9 һәм 3.10 пунктларында күрсәтелгән документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү рәвешендә үткәрелә.

3.8. Планнан тыш тикшерүләр.

3.8.1. Планнан тыш тикшерүне оештыру тәртибе Административ регламентның 3.7.1 пунктында билгеләнгән.

3.8.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торалар:

1) 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозуны бетерү турында Идарә биргән күрсәтмәнең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан, шулай ук Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез

милекнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү өлешендә башка таләпләрне үтәү срогы чыгу, әгәр күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан мондый вакыт үткәнчегә әлеге күрсәтмәдә күрсәтелгән бозулар бетерелмәгән булса.

2) Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык хисабында (шул исәптән еллык) һәм (яки) проект декларациясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисабына анализ үткәрү ба-рышында күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектла-рын өлешләп төзүдә катнашу турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре табылганда;

3) тикшерүче органга 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларын, вәкаләтле органның актларын, җирле үзидарә органнары актларын бозу фактлары турында гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгать итүе һәм гаризалары, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясында 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, коммерциячел булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән алынган мәгълүмат керү;

- төзүченең төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк айга читкә китүе;

- 214-ФЗ номерлы Федераль законның мәҗбүри таләпләрен һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын бозу ачыкланган очракта, Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте күрсәтмәсе нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү үткәрү турында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы;

6) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе.

3.8.3. Административ регламентның 3.8.2 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш тикшерү күрсәтмәдә күрсәтелгән бозуларны бетерү өчен билгеләнгән вакыт чykканнан соң 30 эш көне эчендә үткәрелә.

3.8.4. Әлеге статьяның 11 өлешендәге 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш урынга чыгып тикшерү «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнарына хәбәр итеп, тикшерүче орган тарафыннан кичектергесез үткәрелергә тиеш.

Дәүләт функциясе үтәлә торган затка карата әлеге нигез буенча планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

3.8.5. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы затлар Административ регламентның 3.7.3 пунктында күрсәтелгән.

3.8.6. Административ регламентның 3.8.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш урынга чыгып тикшерүдән тыш, планнан тыш тикшерү үткәрү турында аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка Бүлек тарафыннан боерык һәм таләп җибәрү/тапшыру юлы һәм мәгълүмат алуны билгеләргә мөмкинлек бирә торган теләсә кайсы ысул белән аны уздыра башлаганчы 24 сәгать алдан хәбәр ителә.

3.8.7. Планнан тыш тикшерү Административ регламентның 3.9 һәм 3.10 пунктларында күрсәтелгән документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү рәвешендә үткәрелә.

3.9. Документларны тикшерү.

3.9.1. Документар тикшерү предметы булып, аларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган аларга карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затларның документларында булган мәгълүматлар, эшчәнлеген башкарганда кулланыла торган һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү белән бәйле документлар тора.

3.9.2. Документар тикшерүләр Бүлекнең урнашу урыны буенча үткәрелә.

3.9.3. Документар тикшерүне оештыру (планлы һәм планнан тыш) гамәлгә ашырыла:

3.9.3.1. Һәр хисап елы башында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе имзасы белән карар чыгару юлы белән - төзүчеләрнең хисабын квартал саен тикшерү, проект декларацияләре һәм аларда кертелә торган үзгәрешләр (өстәмәләр) мәсьәләләре буенча, төзүчеләр һәм төзелешне финанслаучы затлар арасында хокукый мөнәсәбәтләрне тикшерү, агымдагы мониторинг һәм массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге басмаларны анализлау нәтиҗәләре буенча, төзелеш объектларына чыгуларның нәтиҗәләре буенча.

Әлеге карарда Бүлек хезмәткәренең квартал саен хисап бирмәүче гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итүче төзелеш оешмаларын, белешмәләр, проект декларацияләре һ. б. ачыклау бурычы теркәлә.

3.9.3.2. Административ регламентның 3.7.1 пунктында билгеләнгән тәртиптә - төзүченең гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле күпфатирлы йорт, торак комплексы яки башка күчемсез милек объектын төзүгә барлык эшчәнлеген өлешле төзелеш турындагы законнарны үтәү предметына тикшерү мәсьәләсе буенча.

3.9.4. Тикшерү үткәрү өчен вәкаләтле Бүлек хезмәткәренеңтикшерү үткәргәндә хокуклары һәм бурычлары административ регламентның 1.9.1 һәм 1.9.2 пунктлары белән билгеләнә.

3.9.5. Документар тикшерү барышында Бүлекнең вәкаләтле заты тарафыннан беренче чиратта тикшерү субъектларының Бүлек карамагында булган документлары карала.

3.9.6. Бүлек карамагында булган документларда булган мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса яки бу мәгълүматлар тикшерү субъектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, Бүлек хезмәткәре аңа карата дәүләт функциясе үтәлүче зат исеменә документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны, белешмәләрне, мәгълүматны,

аңлатма бирүне таләп итеп мотивлаштырылган сорату җибәрә.

Төзүчедән соратып алына торган документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелеш өчен гражданнар акчаларын җәлеп итүче затлардан алынган күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлеге турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары белән расланган. Таләп Башкарма комитет җитәкчесе, яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

Әгәр документар тикшерү Административ регламентның 3.9.3.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча үткәрелсә, тикшерелүче зат адресына җибәрелә торган таләпкә документар тикшерү үткәрү турында Карар күчермәсе теркәлә.

3.9.7. 10 эш көне эчендә яисә мотивациялә\u043dгән сорату алган көннән башлап сорату (таләп) билгеләгән башка тиешле срокта аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган зат соратуда күрсәтелгән документларны, мәгълүматны, белешмәне, аңлатмаларны Бүлеккә җибәрергә бурычлы.

3.9.8. Соратуда (таләптә) күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр Бүлеккә мөһер (булган очракта) һәм төзүче җитәкчесе имзасы белән расланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

Документларны вәкаләтле зат раслаган очракта, мондый вәкаләтләр булуны раслаучы документлар тапшырыла.

Документларны тапшырганда, төзүченең җитәкчесе кул куйган һәр документның исемен күрсәтеп, исемлек төзелә. Әлеге исемлек кәгазьдә тапшырыла.

Таләп ителгән документлар һәм (яки) белешмәләр булмаганда, озату хатында әлеге таләпне үтәү мөмкин булмаган хәлләр күрсәтелә (мәсәлән, заем акчалары җәлеп ителмәгән, шартнамә төзелмәгән, милек хокукы теркәлмәгән һәм алга таба).

3.9.9. Әгәр дә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган заттан Бүлеккә тапшырыла торган документлар күчермәләренең нотариаль таныклануын таләп итү рөхсәт ителми.

3.9.10. Документар тикшерү барышында аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланса, яисә документларда булган белешмәләрнең Бүлектә булган белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, бу хакта мәгълүмат аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затка 10 эш көне эчендә язма формада кирәкле аңлатмаларны тәкъдим итү таләбе белән мәгълүмат алуны билгеләргә мөмкинлек бирә торган теләсә нинди үтемле ысул белән җибәрелә.

3.9.11. Документар тикшерү үткәрә торган затлар аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи зат, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан алдан бирелгән документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм документларны карарга тиеш. Тәкъдим ителгән аңлатмалар һәм документлар каралганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда, өлешләп төзү турындагы законнарның мәҗбүри таләпләрен бозу билгеләре билгеләнсә, тикшерү үткәрүгә вәкаләтле Бүлекнең заты урынга чыгып тикшерү уздырырга хокуклы.

3.9.12. Документар тикшерү үткәрү вакыты 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

3.9.13. Тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү, тикшерү нәтиҗәләрен

рәсмиләштерү.

3.9.13.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар тарафыннан Административ регламентка 3-нче кушымта нигезендә форма буенча тикшерү акты төзелә.

3.9.13.2. Тикшерү акты өч эш көне эчендә турыдан-туры аны тәмамлаганнан соң 3 нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе кушымталар күчермәләре белән (булганда) тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында язу астында җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки тикшерү субъектының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла.

3.9.13.3. Тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле документлар куелырга мөмкин.

3.9.13.4. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә аңа карата дәүләт функциясе үтәлә торган затның вәкаләтле вәкиле, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерү субъектының тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә, ул Бүлектә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерү акты төзүченең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза куеп фактик алынганнан соң яисә хәбәрнамә белән заказлы хат алу турында почта тамгасы нигезендә тикшерү субъекты тарафыннан алынган булып санала.

3.9.13.5. Документларны тикшерү үткәрә торган Бүлекнең вәкаләтле заты тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча:

1) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә бозулар ачыкланган очракта, Административ регламентның 1.8.2 пунктында күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып, тикшерү акты төзелә;

2) өлешләп төзү турындагы закон таләпләрен бозуларны бетерү кирәклеген ачыклаганда яисә өлешләп төзүдә катнашучыларның һәм күпфатирлы йортны яки башка күчемсез милек объектын финанслау һәм төзүгә бәйле башка затларның бозылган хокукларын торгызу максатларында, 214-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында төзүче адресына, Административ регламентка 2-нче кушымта нигезендә форма буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә чыгарыла;

3) җинаять билгеләре ачыкланганда, җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына хат җибәрелә.

3.9.13.6. Күрсәтмәләрнең үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат булып, Бүлек хезмәткәре тора.

3.9.13.7. Күрсәтмәне үтәү турында документларны (мәгълүматларны) тапшырмау, тулы булмаган күләмдә яки ялган рәвештә тапшыру административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 4 өлешендә каралган административ җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

3.9.13.8. Коммерция, хезмәт, башка серне тәшкил итүче мәгълүматны үз эченә алган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

3.9.13.9. Аларга карата дәүләт фукциясе үтәлә торган затлар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алган

көннән өч эш көне эчендә Бүлеккә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган бозуларны гомумән яисә аның аерым нигезләмәләрен бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата каршылыкны язма формада тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта аларга карата дәүләт функциясе үтәлә торган затлар мондый каршылыкларның нигезле булуын раслаучы документларны яки аларның расланган күчермәләрен теркәргә яки аларны турыдан-туры Бүлеккә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерү субъектының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелә ала.

3.9.14. Тикшерүләрне теркәү һәм исәпкә алу.

3.9.14.1. Бүлек үткәргән барлык тикшерүләр теркәлергә һәм исәпкә алынырга тиеш.

3.9.14.2. Бүлекнең вәкаләтле хезмәткәре һәр тикшерү тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә яки аның вәкаләтле затына, тикшерү материалларын тәкъдим итеп, дәүләт функциясен үтәү турында телдән хәбәр итәргә тиеш.

3.9.14.3. Тикшерүләрне исәпкә алу журналын алып баруны, шулай ук күрсәтелгән эш башкаруны контрольдә тотуны күздә тоткан тикшерүләр үткәргәндә, эш башкаруны алып бару бурычлары Бүлектә бүлек хезмәткәренә йөкләнә.

Магнит саклагычында ай саен саклау һәм календарь елы башыннан алып биш ел дәвамында үсә торган нәтиҗә белән кәгазь чыганакта ел саен архивлаштыру шартларында, исәпкә алу журналларын электрон рәвештә алып бару рөхсәт ителә.

Исәпкә алу журналларын алып бару вакыты өч ел тәшкил итә. Тәмамланган исәпкә алу журналларын саклау срогы - өч ел. Исәпкә алу журналлары тегелгән, номер сугылган һәм мөһер белән расланган булырга тиеш .

3.10. Урынга чыгып тикшерү.

3.10.1. Урынга чыгып тикшерү предметы булып тикшерү субъектлары документларындагы һәм квартал саен хисап составында Бүлеккә тапшырыла торган мәгълүматларны, шулай ук тикшерү субъектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча күрелә торган чараларны тикшерү тора.

3.10.2. Урынгы чыгып тикшерү (планлы да, планнан тыш та) тикшерү субъектларының урнашкан урыны буенча, аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

3.10.3. Документар тикшерү вакытында мөмкин булмаган очракта урынга чыгып тикшерү үткәрелә:

1) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле, төзүченең квартал саен хисабындагы һәм (яки) Бүлек карамагында булган тикшерү субъектларының башка документларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген таныкланырга;

2) тикшерү субъектлары эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чаралар үткәрмичә бәяләү.

3.10.4. Урынга чыгып тикшерү Бүлекнең вазыйфаи заты тарафыннан хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, тикшерү субъекты җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, аның вәкаләтле вәкилен урынга чыгып тикшерү билгеләү турында Башкарма

комитет боерыгы һәм урынга чыгып тикшерү үткәрә торган затларның вәкаләтләре белән, шулай ук урынга чыгып тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре белән мәҗбүри таныштырудан башлана.

3.10.5. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки тикшерү субъектының вәкаләтле вәкиле, аның вәкаләтле вәкиле урынга чыгып тикшерүне үткәрүче Бүлекнең вазыйфаи затына максатлар, бурычлар һәм күчмә тикшерү предметы белән бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр урынгы чыгып тикшерү алдыннан документар тикшерүе үткәрелмәгән булса, шулай ук урынгы чыгып тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның тикшерү объектлары территориясенә керүен тәэмин итәргә тиеш.

3.10.6. Планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче яисә юридик затның башка вазыйфаи затының булмавы яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең фактта башкарылмавы яисә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкчесе яисә юридик затның башка вазыйфаи затының башка гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле рәвештә тикшерү үткәрү мөмкин булмаган очракта, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында, мөмкин булмауның сәбәпләрен күрсәтеп, акт төзи. Бу очракта муниципаль контроль органы тиешле тикшерүне уздыруның мөмкин булмавы турында акт төзелгән көннән соң өч ай эчендә планлы тикшерүнең еллык тикшерү планына кертмичә, шәхси эшмәкәргә, юридик затка алдан хәбәр итмичә, шундый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

3.10.7. Тикшерү барышында вазыйфаи затның һәм вәкаләтле Бүлек хезмәткәренең хокуклары һәм бурычлары Административ регламентның 1.9.1 һәм 1.9.2 пунктларында күрсәтелгән.

3.10.8. Тикшерү барышында Бүлек хезмәткәре тикшерү субъектларын Административ регламент белән таныштырырга тиеш.

3.10.9. Урынга чыгып тикшерүне үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артмаска тиеш. Кече эшмәкәрлек субъектларына карата планлы урынга чыгып тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятиеләр өчен елына 50 сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен елына 15 сәгатьтән артмаска тиеш.

3.10.10. Тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү, тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

3.10.11. Тикшерү үткәрүче вәкаләтле Бүлек хезмәткәре тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә. Тикшерү акты ул тәмамланганнан соң өч нөсхәдә турыдан-туры рәсмиләштерелә, шуларның берсе кушымталар күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки лицензиатның вәкаләтле вәкиленә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка биреп тапшырыла.

3.10.11.1. Тикшерү актына вәкаләтле хезмәткәрләрнең һәм (яки) тикшерү субъекты җитәкчесенең, документлар яки аларның күчермәләрен кушып, аңлатмалары теркәлә.

3.10.11.2. Тикшерү субъекты җитәкчесе, башка вазыйфаи зат яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерү субъекты тикшерү акты белән танышу

яки танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә, ул делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

3.10.12. Тикшерү үткәрә торган вәкаләтле Бүлек хезмәткәре тарафыннан урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча:

1) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә бозулар ачыкланган очракта, тикшерү акты Административ регламентның 1.8.2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып төзелә;

2) административ җәза каралмаган мәҗбүри таләпләрне бозуларны ачыклаганда, Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә бирелгән форма буенча килеп чыккан бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелә;

3) җинаять билгеләре ачыкланганда, җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына хат җибәрелә. Күрсәтмә анда билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш.

Бүлекнең вазыйфаи заты урынга чыгып тикшерү рәвешендә күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тота.

3.10.12.1. Күрсәтмәне үтәү турында документларны (мәгълүматларны) тапшырмау, тулы булмаган күләмдә яки ялган рәвештә тапшыру административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясында каралган административ җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

3.10.12.2. Коммерция, хезмәт, башка серне тәшкил итүче мәгълүматны үз эченә алган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

3.10.12.3. Тикшерү субъектлары Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган типлаштырылган форма буенча тикшерүләр исәбен алу журналын алып барырга хокуклы.

3.10.12.4. Тикшерүләрне исәпкә алу журналында Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт контроле органы белешмәләрен, тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану датасын, үткәрү вакытын, хокукый нигезләр, максатлары, бурычлары һәм тикшерү предметлары, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр кергән үткәрелгән тикшерү турында язма гамәлгә ашырыла, шулай ук тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме һәм вазыйфасы, тикшерү үткәрүче вазыйфаи имзасы күрсәтелә.

3.10.12.5. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән, номерланган һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр мөһере белән расланган булырга тиеш.

3.10.12.6. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язу ясала.

3.10.12.7. Тикшерү субъектлары тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алган көннән алып өч эш көне эчендә тикшерү акты һәм (яки) ачыкланган бозуларны тулаем яисә аның аерым

нигезләмәләрен бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата каршылыкларны язма рәвешендә бүлеккә тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта тикшерү субъектлары мондый каршылыкларга мондый каршылыкларның нигезле булуын раслаучы документларны яки аларның расланган күчермәләрен беркетергә яисә аларны турыдан-туры бүлеккә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерү субъектының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелә ала.

3.10.12.8. Урынга чыгып тикшерүләрне теркәү һәм исәпкә алу Административ регламентның 3.9.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11. Төзүче һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә мондый бәяләмәне бирүдән мотивлаштырылган баш тарту аерым административ регламент белән җайга салына.

3.12. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисаплыгын тикшерү.

3.12.1. Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсеннән өлешләп төзелештә беренче катнашу шартнамәсен теркәү турында хәбәрнамә алу административ процедураны үти башлауга нигез булып тора.

3.12.2. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы Бүлекнең вәкаләтле заты булып Бүлек хезмәткәре тора.

3.12.3. Хисаплылык тәкъдим ителергә мөмкин:

- турыдан-туры Бүлеккә;
- почта аша турыдан-туры Бүлеккә җибәрү рәвешендә.

Кабул ителгән хисаплык электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасында (алга таба – ЭДӘВС) теркәлергә тиеш.

3.12.4. Хисаплылык хисап кварталы тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча һәм IV квартал тәмамланганнан соң 90 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Шул ук вакытта оешманың хисап бирү көне буларак кертемнәр исемлеге белән почта җибәрү датасы исәпләнә.

3.12.5. Төзүчедән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен хисап кабул итү административ процедурасы төзүченең хисаплылыгы белән Бүлеккә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисаплылыгы хакында» 2005 елның 27 октябрендәге 645 номерлы карары белән билгеләнгән формалар нигезендәге форма буенча хисап тапшырудан башлана.

3.12.6. Хисаплылык төзүче тарафыннан юридик зат җитәкчесе имзасы белән озату хаты белән язма формада тапшырыла. Хисап Бүлеккә кергәннән соң, хисап тикшерүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле хезмәткәр:

- хисапның барлык формалары булуын, бухгалтерлык балансын һәм аларның мәгънәле һәм санлы кыйммәтен тикшерә;

- язма формада тәкъдим ителгән хисап битләре тегелгән, номерланган, төзүченең җитәкчесе яки аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзаланган, шулай ук хисап төзү өчен җаваплы зат тарафыннан имзаланган, шулай ук төзүченең мөһере белән беркетелгән булуын тикшерә;

- төзүченең башка чыгымнарының булуы турындагы мәгълүматны ачыклый, андый чыгымнар булган очракта, акчаларны тоту юнәлешен күрсәткән белешмә һәм проект декларациясенә сылтамалар кабул итә;

- өлешләп төзү объектын өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру срокларын төзүче тарафыннан үтәүне тикшерә. Шартнамәләр буенча үтәлмәгән (срогы чыккан) йөкләмәләр булганда йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәү сәбәпләре турында белешмә булуны тикшерә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында проект декларациясен урнаштыру турында мәгълүматларның булу-булмавын тикшерә;

- төзүченең финанс тотрыклылыгы нормативларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2006 елның 21 апрелендәге 233 номерлы карары таләпләренә туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра.

3.12.7. Административ регламентның 3.13.6 пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән бозуларны билгеләгәндә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган документлар булмаганда, белгеч төзүчегә күрсәтмә җибәрә яки Административ регламентка 1, 2-нче кушымталар нигезендә билгеләнгән форма буенча тикшерү акты төзи.

3.12.8. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2.3 өлешендә күрсәтелгән фактлар ачыкланганда («Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясынлагы 7 өлешен исәпкә алып), Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тиешле карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүчедән 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2.3 өлешендә күрсәтелгән карарлар теркәлгән күпфатирлы йортлар төзелешенә (тудыруга) өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның акчаларын җәлеп итү хокукы булмау турында хәбәрнамә җибәрелә.

3.12.9. Административ процедураны үтәүнең максималь вакыты 60 эш көне тәшкил итә.

3.12.10. Хисапларны карау йомгаклары буенча белгеч Административ регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча тикшерү акты төзи.

3.12.11. Өлешле төзелеш объектын өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру вакытын бозу, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 8 статьялары таләпләрен үтәмәү һәм финанс тотрыклылыгы нормативларының туры килмәве ачыкланган очракта, төзүчегә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелә.

3.12.12. Административ җаваплылык каралган закон бозу очраклары ачыклан-ган очракта, акт материаллар белән хокук саклау органнарына, шул исәптән, административ хокук бозу турында эш кузгату өчен, Түбән Кама шәһәре прокуратурасына җибәрелә. Шул ук вакытта күрсәтмәләрнең үтәлмәве буенча материаллар күрсәтмәне үтәү срогы тәмамланганнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

3.12.13. Хисапларның төп нөсхәләре Бүлектә саклана, аларны бирү хокук саклау һәм суд органнары таләпләре буенча күздә тотыла.

3.12.14. Өлешләп төзүдә катнашучыларның һәм төзүчеләрнең өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы төзүченең квартал саен хисапларын тикшерү нәтиҗәләренә (алга таба – тикшерү нәтиҗәләре) үтемлелеген тәэмин итү максатында, тикшерү нәтиҗәләрен гомумиләштерү үткәрелә.

Тикшерү нәтиҗәләрен гомумиләштерү Бүлек сайтында башкарыла.

3.12.15. Төзелеш проектларын тормышка ашыруның тәкъдим ителгән якынча графикларының туры килүен бәяләүне гамәлгә ашыру максатында (алга таба – графиклар) күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын карау үткәрелә.

Барлык объектларны карау вакыты тиешле материаллар алганнан соң 30 календарь көннән артмаска тиеш.

Объектларны карап тикшерү нәтиҗәләре карап тикшерүне гамәлгә ашыручы бүлек хезмәткәре тарафыннан графикка кертелә һәм карап тикшерә торган вазыйфаи зат оешмасы мөһере белән таныклана. Объектларның төзелеш әзерлеге дәрәҗәсе төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларына туры килмәсә, графикка төзүче күрсәткән фактик мәгълүматлар белән тиешле искәрмәләр «/» билгесе белән кертелә.

3.13. Күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыру.

3.13.1. Торак-төзелеш кооперативын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру административ процедураны үтәүгә нигез булып тора.

3.13.2. Күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә дәүләт контроле Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләре нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле төзүчеләрнең эшчәнлеген контрольдә тоту турында 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.13.3. Күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген тикшерү предметы булып тора:

- күпфатирлы йортны киләчәктә кара тотудан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше таләпләрен үтәү;

- Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы таләпләрен үтәү өлешендә торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеге;

- торак кооперативы вазыйфаи затларының Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе.

3.13.4. Административ процедура 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында билгеләнгән тәртиптә документар һәм (яки) күчмә формада планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә үткәрелә.

3.13.5. Дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләргә ия булган Бүлек хезмәткәре булып Бүлекнең баш белгече тора.

3.13.6. Административ процедураны уздырганда тикшереләләр:

торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында түбәндәге документларны һәм мәгълүматны урнаштыру:

- торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының саны турында мәгълүмат;

- төзелештә торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үз акчалары белән катнаша торган күпфатирлы йорт төзелешенә рөхсәт;

- җир кишәрлегенә торак-төзелеш кооперативының хокуклары турында мәгълүматлар, шул исәптән җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документ реквизитлары, җир кишәрлеге хуҗасы турында мәгълүматлар (торак-төзелеш кооперативы җир кишәрлегенең милекчесе булмаса), күпфатирлы йорт төзү өчен бирелгән җир кишәрлегенең кадастр номеры һәм мәйданы турында, төзекләндерү элементлары турында мәгълүматлар;

- төзелә торган күпфатирлы йортның урнашу урыны турында мәгълүмат һәм аның нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән проект документациясе нигезендә әзерләнгән тасвирламасы;

- төзелеп килүче күпфатирлы йортта торак биналарның саны турында мәгълүматлар, проект документлары нигезендә мондый торак биналарның техник характеристикалары тасвирламасы, шулай ук проект документациясенә тиешле үзгәрешләр кертелгән очракта үзгәртелгән мәгълүмат;

- төзелеп килүче күпфатирлы йортны файдалануга тапшыруга рөхсәт алу вакыты турында мәгълүмат;

- кооператив уставы;

- кооператив әгъзалары Реестры;

2) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясындагы 3 өлеше таләпләре нигезендә белешмәләр булган кооператив әгъзалары реестрын алып бару;

3) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләренең таләпләрен үтәү;

4) катның саны өчтән артмаган бердән артык булмаган күпфатирлы йортны бер үк вакытта төзүне гамәлгә ашыру буенча таләпләрне үтәү.

3.13.7. Торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрындагы мәгълүматлар, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясында каралган башка мәгълүматны вазыйфаи затлар торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан ала.

3.13.8. Планлы тикшерү үткәрү өчен нигез булып, торак-төзелеш кооперативына төзелеш алып бару өчен рөхсәтнең бирелгән датасыннан бер ел үтү яисә төзелеш гамәлгә ашырыла торган Россия Федерациясе субъекты территориясендә мондый кооперативны соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланганнан соң бер ел үткән булу тора.

Административ регламентның 3.13.6 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматны тикшерү күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә.

Тикшерүне оештыру һәм үткәрү тәртибе административ регламентның 3.7, 3.9 һәм 3.10 пунктларында бәян ителгән. Тикшерү үткәрү вакыты биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

3.13.9. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы һәм алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше таләпләрен бозуларны бетерү турында тикшерү органы биргән күрсәтмәне торак-төзелеш кооперативы тарафыннан үтәү срогы чыгу;

2) тикшерү органына гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгате һәи гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат керү, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьялары таләпләрен бозу фактлары турында системадан мәгълүмат керү;

3) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе.

Тикшерү үткәрү вакыты 20 эш көненнән артмаска тиеш.

3.13.10. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан билгеләнгән срокта ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр үтәлмәгән очракта, шулай ук әлеге бозулар торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә реаль куркыныч тудырса, Бүлек хезмәткәре тарафыннан кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы тарафыннан тиешле хокук бозуларны бетергәнчегә кадәр торак-төзелеш кооперативының эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә чыгарылырга мөмкин. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Бүлекнең баш белгече чыгарган күрсәтмә үтәлмәгән очракта, Бүлек әлеге кооперативны бетерү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.14. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау.

3.14.1. Административ процедураның башы булып, Бүлеккә гражданнан яисә оешмадан дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать яки гариза керү тора.

3.14.2. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча гражданнан яисә оешмадан мөрәҗәгать яисә гариза 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.14.3. Бүлек хезмәткәре өч эш көне дәвамында кергән мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән документларны карый һәм документларда резолюция әзерли.

3.14.4. 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән фактлар турында тиешле мәгълүматлар, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, Бүлек белгече тарафыннан алынган мәгълүмат алдан

тикшерелергә мөмкин.

3.14.5. Кергән мәгълүматны алдан тикшерү барышында, мәгълүмат биргән, гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән затлардан өстәмә мәгълүмат һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, Бүлек белгече карамагында булган юридик зат, шәхси эшмәкәр документларын карау үткәрелә, кирәк булганда, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешкә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат тапшыру һәм Бүлек таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә, тикшерү буенча чаралар үткәрелә.

3.14.6. Алдан тикшерү кысаларында аларга карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затлардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, әмма мондый аңлатмалар һәм башка документлар тапшыру мәҗбүри түгел.

3.14.7. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган затларны алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыклаганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар алганда, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик зат, шәхси эшкуарны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

Мәҗбүри таләпләрне бозган затларны алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында мәгълүмат алганда, Бүлек белгече планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли.

3.14.8. Әгәр алдан тикшерү башланганнан соң аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның аноним булуы ачыкланган яки мөрәҗәгатьтә яки гаризада булган белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта, Бүлек хезмәткәре карары буенча алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

3.14.9. Мөрәҗәгатькә җавап Башкарма комитет җитәкчесе, яисә аның вәкаләтле зат тарафыннан имзалана.

3.14.10. Электрон документ формасына кергән гаризага яки мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча яисә (мөрәҗәгать электрон формада кергәндә) электрон документ формасында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча җибәрелә.

3.14.11. Административ процедураны үтәү нәтиҗәләрен теркәү ЭДӘВС башкарыла.

3.14.12. Административ процедураның нәтиҗәсе булып Бүлекнең мөрәҗәгатькә җавабы тора.

## 4. Дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру Административ регламенты үтәлешен контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Административ регламент һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләрен тотуын һәм үтәлешен агымдагы тикшерү, шулай ук карарлар кабул итү Башкарма комитет җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.1. Дәүләт функциясе үтәлешенә агымдагы контроль Бүлекнең вәкаләтле заты тарафыннан кабул ителә торган гамәлләр һәм карарларга планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

Планлы тикшерүләр үткәрү вакыты аралыгы һәм сроклары:

- ай саен - күчмә һәм документар тикшерүләр нәтиҗәләрен тикшергәндә;

- квартал саен - камераль тикшерүләр актларын сайлап алганда тикшергәндә.

4.1.2. Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү барышында тикшереләләр:

- күчмә һәм документар тикшерүләр үткәрү сыйфаты, тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе;

- төзүчеләрнең финанс тотрыклылыгы нормативларын исәпләү дөреслеге;

- төзүче һәм проект декларациясенең билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында (мотивлаштырылган баш тарту) бәяләмә бирү нигезләре.

4.1.3. Планнан тыш тикшерүләр бүлеккә вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять биргән мөрәҗәгатьләрне карап тикшергәндә үткәрелә.

4.1.4. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт функцияләрен үтәү буенча карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм дәүләт функциясен үтәгәндә кабул ителгән карарларына кызыксынган зат тарафыннан язма рәвештә яисә электрон документ формасында шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук телдән (шәхси кабул иткәндә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелергә мөмкин.

5.1.1. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы дәүләт функциясен үтәүдә катнашучы Бүлекнең вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм дәүләт функцияләрен үтәү барышында кабул ителгән карарлар.

5.1.2. Шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада Бүлеккә тапшырыла.

5.1.3. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен кулланып, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайты аша җибәрелергә мөмкин (http://www.e-nkama.ru), шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.1.4. Шикаять үз эченә ала:

1) дәүләт функциясен үтәүче орган исеме, аларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаять белдерелә торган вазыйфаи затның, дәүләт хезмәткәренең, дәүләт функциясен үтәүче орган белгеченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), мөрәҗәгать итүче физик затның яшәү урыны турында белешмә яисә мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашу урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (-лары), электрон почта адресы(-лары) (булса) һәм шикаятькә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) шикаять бирелә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) вазыйфаи затның карары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) белән килешмәү нигезендә дәлилләр.

5.1.5. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.1.6. Әгәр шикаять мөрәҗәгать итүче вәкиле аша бирелсә, шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән эшләрне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен раслаучы документ тапшырыла.

5.1.7. Бүлеккә кергән шикаять кергән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.1.8. Бүлеккә кергән шикаять шикаятьне карау өчен вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан карап тикшерелергә тиеш, ул тәэмин итә:

1) 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә шикаятьләрне кабул итү һәм карау;

2) мөрәҗәгать итүчеләргә аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозучы карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерү тәртибе турында хәбәр итү.

5.1.9. Шикаять Бүлектә теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.1.10. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бүлеккә аның компетенциясенә керми торган шикаять бирелгән очракта, шикаять Бүлектә теркәлгән көннән соң җиде эш көне эчендә аны карарга вәкаләтле органга җибәрелә, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә хәбәр ителә. Шул ук вакытта шикаятьне карау срогы аны карарга вәкаләтле органда шикаять теркәлгән көннән исәпләнә.

5.1.11. Шикаятьне карауны туктатып тору каралмаган.

5.1.12. Бүлекнең шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алырга хокуклы.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет җитәкчесе, яисә аның вәкаләтле вәкиле түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсендә төзелгән документларда җибәрелгән басмадагы хата һәм хаталарны төзәтү рәвешендә дә канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.1.13. Карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) язмача формада һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.1.14. Бүлек түбәндәге очракларда шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) шул ук предмет һәм шул ук нигезләргә шикаять буенча суд, арбитраж судның законлы көченә кергән карары булу;

2) вәкаләтләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган зат тарафыннан шикаять бирү;

3) шул ук мөрәҗәгать итүчегә карата һәм шул ук шикаять предметы буенча Административ регламент таләпләре нигезендә элегрәк кабул ителгән шикаять

буенча карар булу;

4) шикаятьне нигезсез дип тану;

5) шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча җинаять билгеләре булу. Бу очракта шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавапта күрсәтелә:

а) шикаять буенча карар кабул иткән Бүлекнең вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) ;

б) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) яки мөрәҗәгать итүче юридик затның исеме;

в) шикаять буенча карар кабул итү нигезләре;

г) шикаять буенча кабул ителгән карар;

д) әгәр шикаять нигезле дип табылса – ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү сроклары;

е) шикаять нигезсез дип табылса – шикаятьне нигезсез дип тану сәбәпләре һәм мөрәҗәгать итүченең суд тәртибендә кабул ителгән карарка шикаять бирү хокукы турындагы мәгълүмат;

ж) шикаять буенча кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүматлар.

5.1.15. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавап Башкарма комитет җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

Мөрәҗәгать итүченең теләге буенча шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җавап карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, аның төре Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән, шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затның һәм (яисә) шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле органның электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга мөмкин.

5.1.16. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шикаять буенча кабул ителгән карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

5.1.17. Дәүләт функциясен үтәү буенча карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәсе булып, шикаятьне канәгатьләндерү яисә шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карарны үз эченә алган мөрәҗәгать итүчегә җавап тора.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт функциясен үтәү буенча Административ регламентка
1-нче кушымта

Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуны бетерү турында
КҮРСӘТМӘ

20__ елның «____»__________ №______

______________________________________________________________________
(күчемсез милек объекты адресы)

адресы буенча урнашкан күчемсез милек объектын төзегәндә, күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек Бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшерү уздырылды.

Тикшерү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу очраклары ачыкланды:

| т/с | Норматив документ пункты номеры | Җитешсезлекләргә характеристика | Җитешсезлекләрне бетерү сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Күрсәтелгән җитешсезлекне җибәргән
______________________________________________________________________.
(юридик затның исеме)

Бүлек баш белгеч______________________________________йөзендә, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, күрсәтмә бирә:

______________________________________________________________________
(юридик зат исеме, җитәкченең Ф.И.О.)

20__ елның «__»_______ кадәр срокта җибәрелгән җитешсезлекләрне бетерергә. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә закон бозуларны юкка чыгаруны раслый торган документлар белән әлеге күрсәтмәнең үтәлеше турында мәгълүматны, яисә тиешле документлар һәм башка материаллар белән расланган җитешсезлекләрне бетерү буенча кабул ителмәгән чаралар сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге күрсәтмәне үтәү срогын озайту турында үтенечнамәне Бүлеккә түбәндәге адрес буенча тапшырырга: Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Түбән Кама шәһәре, Мәктәп бульвары, 2а йорт.

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 ст. 4 өлеше нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органның законлы күрсәтмәсен билгеләнгән вакытка үтәмәү вазыйфаи затларга ун меңнән унбиш мең сумга кадәр, юридик затларга йөз меңнән ике йөз мең сумга кадәр административ штраф салуга китерә.

_________________________ _________________________________________

(вазыйфа) (вазыйфаи затның Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт функциясен үтәү буенча Административ регламентка
2-нче кушымта

Төзүченең квартал саен хисаплылыгын
камераль тикшерү (документар)
акты

керү №_______ 20___ елның«___» __________

Төзүченең исеме: _________________________________________________.
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Хисап вакыты аралыгы:
Түбәндәге юнәлешләр буенча квартал саен бирелә торган хисаплылыкка тикшерү үткәрелде:

| т/с | Тикшерелә торган мәсьәләләр исеме | Тишерү белән билгеләнгән |
|---|---|---|
| 1 | Хисапны вакытында тапшыру (датасы) | |
| 2 | Тәкъдим ителгән хисапның комплектлылыгы | |
| 3 | Дөрес рәсмиләштерү (имзалар, мөһер, тегеп кую) | |
| 4 | Квартал саен бухгалтер хисабы | |

1-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Төзүче турында мәгълүмат | |

2-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 6 | Төзелешкә рөхсәт булу | |
| 7 | Проект декларациясен бастырып чыгару һәм урнаштыру | |
| 8 | Җиргә милек хокукын дәүләт теркәве (арендалау) | |
| 9 | Өлешләп төзелештә төзелгән шартнамәләр турында мәгълүмат | |
| 10 | Өлешләп төзү объектын төзүче тарафыннан тапшыру вакыты | |
| 11 | Төзүченең өлешләп төзүдә катнашу шартнамәләрен үтәве турында мәгълүмат | |

| | | |
|---|---|---|
| 12 | Өлешләп төзелештә катнашу шартнамәләре | |
| 13 | Объектны файдалануга тапшырырга рөхсәт итү турында мәгълүмат | |
| 14 | Белешмәләр булу | |
| | 7 п. - таркалган шартнамәләр буенча белешмә | |
| | 11 п. – йөкләмәләрнең тиешенчә башкарылмавы турында белешмә | |

3-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 15 | Җәлеп ителгән акчалар турындагы мәгълүматларны анализлау | |
| 16 | Башка чыгымнар (проект документациясенә сылтама белән) | |

4-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 17 | Йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы (кимендә 1) | |
| 18 | Чараларны максатчан куллану нормативы (1дән артык түгел) | |
| 19 | Зыянсызлык нормативы (кимендә 1) | |
| 20 | Өстәмә мәгълүмат бирү | |

Тикшерү нәтиҗәсе

Хисаплылык (кабул ителгән, кабул ителмәгән): ____________________.

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозу очраклары ачыкланды -_______________________________________________________.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 27 октябрендәге 645 номерлы карарының 1-5 номерлы пункты, 9-14 пункты таләпләрен бозу очраклары ачыкланды_________________________________________________________.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 апрелендәге 233 номерлы карары таләпләрен бозу очраклары ачыкланды:

| | | |
|---|---|---|
| 15-17 п. | Йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы (кимендә 1) | |
| | Чараларны максатчан куллану нормативы (1дән артык түгел) | |
| | Зыянсызлык нормативы (кимендә 1) | |

Актка кушымта белән листларда хисап теркәлә.

Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең 2006 елның 12 гыйнварындагы 06-2/пз-н номерлы боерыгы белән расланган методик күрсәтмәләрнең 1.4 пункты нигезендә хисап формаларын тутырганда рөхсәт ителми:

- хисап формаларында күрсәтелгән күрсәткечләрнең мәгънәви эчтәлеген үзгәртү;

- хисап формаларында билгеләнгән тәртибен төшереп калдыру яки үзгәртү;

- хисапларның бер графасында берничә күрсәткечне чагылдырырга, шул рәвешле хисап формасының логик структурасын бозу;

- хисап формаларына төзәтүләр кертү.

Хисапны тикшерде: ___________________ (_______________________)
(имза) (фамилиясе, инициаллары)

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелде:
214-ФЗ номерлы 2004 елгы Федераль законның__________________________кадәр;
645 номерлы 2005 елгы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары _________кадәр;
233 номерлы 2006 елгы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары _________кадәр.

Хисапта ачыкланган кисәтүләр бетерелде:
214-ФЗ номерлы 2004 елгы Федераль законның _________________________________;
(әйе яки юк)
645 номерлы 2005 елгы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары _____________;
(әйе яки юк)
233 номерлы 2006 елгы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары____________.
(әйе яки юк)

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт функциясен үтәү буенча Административ регламентка
3-нче кушымта

## Дәүләт функцияләрен үтәү блок-схемасы

### 1. Еллык тикшерүләр планын төзү




### 1. Планлы тикшерүләр оештыру




### 2. Планнан тыш тикшерүләр оештыру



## 3. Урынга чыгып тикшерү.




## 3.1. Урынга чыгып тикшерү үткәрү




## 4.2. Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләрен эшкәртү



# 4. Документар тикшерү
## 4.1. Документар тикшерүне үткәрү




## 5.2. Документар тикшерү нәтиҗәләрен эшкәртү



Татарстан Республикасы Түбән Кама муни-ципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт функциясен үтәү буенча Администра-тив регламентка
4-нче кушымта

Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен тапшырыла торган хисап белән төзүче тарафыннан тәкъдим ителә торган документлар исемлеге

1. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (тудыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисабы.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүченең квартал саен хисабы хакында» 2005 елның 27 октябрендәге 645 номерлы карары белән расланган өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисап тапшыру Кагыйдәләренең 2 пункты нигезендә (алга таба – Кагыйдәләр) хисап составына түбәндәгеләр кертелә:

1) Кагыйдәләргә 1-4 номерлы кушымталар нигезендәге формалар буенча хисаплар;

2) Кагыйдәләр белән билгеләнгән очракларда тапшырыла торган белешмәләр:

- өзелгән шартнамәләр булганда, хисап чорында һәр шартнамәне өзү нигезләрен күрсәтеп, белешмә тапшырыла;

- шартнамәләр буенча үтәлмәгән (срогы чыккан) йөкләмәләр булганда, йөкләмәләрне тиешенчә башкармау сәбәпләрен күрсәтеп белешмә тапшырыла;

- башка чыгымнар булганда, акчаларны тоту юнәлешен һәм акчаларны тотуның шушы юнәлешен күз алдында тоткан проект документациясенә сылтама күрсәтеп, белешмә тапшырыла;

3) квартал саен (IV квартал нәтиҗәләре буенча – еллык) төзүченең Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтер хисабы. Еллык бухгалтер хисабы составында төзүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның соңгы елына аудитор бәяләмәсе бирелә.

2. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә тикшереп торуны һәм күзәтүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына төзелеш

өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан өлешләп төзелештә катнашуның төзелгән шартнамәләре реестры.

3. Күпфатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзегәндә (тудыргавда) төзүче башкарган эшләр күләме турында белешмә.

4. Тиешле рәвештә расланган күчермәләре (тапшырылган белешмәләрне раслау өчен):

- күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзелешенә рөхсәт*;

- күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзү (тудыру) өчен бирелгән җир кишәрлегенең милек хокукын һәм (яки) аренда (субаренда) шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, дәүләт теркәве турында билге белән*;

- өлешләп төзүдә катнашуның беренче теркәлгән шартнамәсе;

- күпфатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр*;

- өлешләп төзү объектын төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру турында яклар тарафыннан имзаланган тапшыру акты яки башка документ.

* Күрсәтелгән документлар төзүче инициативасы буенча гына тапшырылырга мөмкин.